СОВЕТ МОРТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ МОРТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **с.Морты** **КАРАР**

№ 94 «15» май 2023 ел.

**Җирле салымнар суммасы буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану өчен өстәмә нигезләр билгеләү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының» Морт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Морт авыл җирлеге Советы

**КАРАРЫ:**

1. Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1.1. физик затның үлеменнән соң өч еллык срокның тәмамлануы яки аны гражданлык процессуаль законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителүе, әгәр варислар булмаса, закон буенча да, васыять буенча да, варисларның берсе дә мирас алудан читләштерелмәсә, яки варисларның берсе дә мирас алудан баш тартса, яисә варисларның барысы да мирас алудан баш тартса, һәм аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәсә;

1.2. салым түләүченең гражданнарга стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада булуы;

1.3.салым салу объекты булган милеккә милек хокукы туктатылган көннән алып өч еллык срокның тәмамлануы;

1.4. җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү буенча бурыч барлыкка килгән көннән алып өч еллык срок тәмамлану.

2. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Морт авыл җирлеге Советының «җирле салымнар буенча бурычларны, пенялар һәм штрафлар

буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында»23.06.2014 № 141 карары үз көчен югалткан дип танылсын.

3. Әлеге карарны «Новая Кама» газетасында, «Алабуга Нуры» газетасында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга, шулай ук рәсми сайтта урнаштырырга: городелабуга.РФ.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Рәисе Ф. Ф. Закиров

Совет Мортовского сельского поселения